

Вакыт бер урында тормый, менә чираттагы ел ахырына якынлаша. Һәр кеше очен ул торле була. Алда безне яна унышлар һәм, бәлки, котелмәгән якты тормыш вакыйгалары очен ишек ача торган яна ел котә. Ин моһиме, барлык вакыйгалар да шатлыклы, ә киләсе ел һәр кеше очен бәхетле елларнын берсе булсын.
Ә бит барыбыздан да бигрәк Яна елны ихластан балалар котә. Алар шатланып бәйрәмгә әзерләнәләр һәм бу эштә армыйталмый ата-аналары, әби-бабайлары да ярдәм итә: торле кул эшләре һәм яна ел рәсемнәре ясыйлар, шигырьләр һәм жырлар ойрәнәләр...
 Мәсәлән, Темниково районы Тархан авылы китапханәчесе һәм авыл клубы хезмәткәре Зульфия Реуф кызы белән Нюрия Шәриф кызы Муратовалар «Исәнме, Яна ел!» кvргәзмәсенә кәгазьдән карчыклар, тосле-тосле рәсемнәр ясаганнар. Ә Митрялы авылы клубы һәм китапханәсе хезмәткәрләре Венера Рәшит кызы Ялышева белән Зәйнәб Шәмил кызы Утешева 
халыкны милли татар телебездә дә котлап матур Чыршы бәйрәме vткәргәннәр, 30 декабрьдә тагы чара vткәргәннәр (фотода милли Кар кызы белән Кыш бабай), халыкны котлап авыл буенча йоргәннәр, Кыш бабай бvләкләрен оләшкән. Мәсәлән, котлау сvзен Садия Загидулла кызы Шехмаметьева видеода: «Ёлка, ёлка без сине, Сагынып коттек ел буе...» дип сойли һәм якташларына ихластан Яна 2026 ел теләкләрен татар һәм рус телләрендә тели. Теләкләрегез кабул булсын, Садия ханым! Инсар социаль яклау бvлеге дә шатлыклы Яна елны котv һәм ижади илһам атмосферасы белән тулы. Бирегә йорvче пенсионерлар зал уртасындагы чыршыны бизәгәннәр һәм аларнын осталары карнавал костюмнары ясау остендә ботен кочләрен куеп эшлиләр. Бәйрәм чын-чынлап якты һәм онытылмаслык булсын очен һәркем vз олешен кертергә тырыша: фотодагы Сания

Нугайбек кызы Исмаилова  ихластан Яна ел барыбыз очен бәхетле булуын тели.
Ин тылсымлы бәйрәм, Яна ел алдыннан Ләмберә районы «Алмаз» мәдәни vзәге vз ишекләрен махсус кунаклар очен ачты! Биредә махсус хәрби операциядә катнашучыларнын гаиләләренә һәм кvп балалы гаиләләргә багышланган игелекле һәм чын-чынлап жылы уен-кvнел ачу программасы  узды. Балалар әниләре



белән бергә рәхәтләнеп Яна ел жырларын жырладылар, кvнелле хәрәкәтчән уеннарда катнаштылар, ә ин дулкынландыргыч мизгелләрнен берсе «Хыял йорты»н бергә тозv булды. Кыш бабай белән Кар кызы балаларны татлы бvләкләре белән соендерделәр. Бәхетле булыр очен бар нәрсәдә дә чик-чама булырга тиеш. Беренчедән, Мордовия Республикасы Матбугат vзәгендә алда торган Яна ел бәйрәмнәрендә жәмәгать тәртибен саклау мәсьәләләре, шулай ук кышкы каникул чорында балаларнын vз-vзләрен куркынычсыз тоту кагыйдәләре турында фикер алыштылар. Барысы турында региональ Эчке эшләр министрлыгынын жәмәгать тәртибен саклауны оештыру идарәсе башлыгы урынбасары Алексей Илиев, Эчке эшләр министрлыгынын Дәvләт автоинспекциясе идарәсе бvлеге башлыгы урынбасары Алексей Сурков, Россия Тикшерv комитетынын РМ буенча Тикшерv идарәсе житәк-чесенен олкән ярдәмчесе Наталья Афанасьева, РФ Гадәттән тыш хәлләр министрлыгынын РМ буенча Баш идарәсенен кvзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше идарәсе башлыгы урынбасары Сергей Соколов сойләде. Юл кагыйдәләрен сакларга да, ут-кvздән сакланырга да онытмыйк. Тагы Яна ел бәйрәмнәре алдыннан Мордовия халкына куркынычсыз-лыкнын топ кагыйдәләре турында республика гадәттән тыш хәлләр министрлыгында искә тошерделәр. Ведомствода узган матбугат кон-ференциясендә Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгынын РМ буенча Баш идарәсе житәкчесе Сергей Репин белән гадәттән тыш хәлләр һәм гражданнар оборонасы эшләре буенча дәvләт комитеты рәисе Андрей Наумов пиротехник эшләнмәләрне, Яна ел иллюминациясен куллану кагыйдәләрен vтәvгә аерым игътибар бирделәр. Тиешле урында пиротехниканы сатып алып, рус тәржемәсе



